РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕШИТЦИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422067, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Нижние Шитцы, ул. Тукая, 15
тел. (84362) 46-4-42

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ШЫТСУ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422067, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Түбән Шытсу авылы, Тукай урамы, 15
тел. (84362) 46-4-42

e-mail: shic.sab@tatar.ru

27.02.2019 № 4

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Түбән Шытсу авыл җирлеге башкарма комитетының
«Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда
тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын
раслау турында " 2016 елның 18 маендагы
24 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Район прокуратурасының 18.02.2019 №02-08-02-25-2019 протесты һәм 2018 елның 27 декабрендәге 558-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп төзүне һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны җайга салучы нормаларны тәртипкә салу өлешендә Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында" гы Федераль закон нигезендә Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл башкарма комитеты карар итте:

1. Түбән Шытсу авыл җирлеге башкарма комитетының «Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 18 маендагы 24 номерлы карары белән расланган “Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрү буенча административ регламенты”на түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3.1 пунктның 6 пунктчасында “әлеге йортта гомуми милекне агымдагы һәм капиталь ремонтлау тәртибе” сүзләреннән соң “күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп планлаштыруны һәм (яки) үзгәртеп төзүне гамәлгә ашыру тәртибе таләпләрен бозу фактлары турында” сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shitsi адреслары буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Түбән Шытсу авыл җирлеге башлыгы: Б.М.Мәүлетов